# АНИКШЧЯЙ УРМАНЫ

И шәрә тау сыртлары, коры төп баскан җирләр,
Кайда ул куе урманны шаулатып искән җилләр?!
...Кайда ул, сезнең кошлар сайраган көннәр кайда?
Җанварлар һәм ерткычлар йоклаган өннәр кайда?
Бернәрсә дә калмаган – исләрең китә карап:
Анда-санда күренә берничә кәкре нарат.
...Бар иде чаклар: монда төннәрен дә, көндез дә
Шаулый иде бу урман охшап яшел диңгезгә.
...Һәр адымда мең төрле хуш исләр аңкый иде,
Мүк арасында җиләк күзләре балкый иде.
...Шул ояда куяннар һәм урман тавыклары
Рәхәттә йоклый иде ямь һәм тәм табып бары.
...Монда безгә һәрнәрсә: „Ал! Ярат! Сайла!“ – диде.
Биредә барча аваз – безнең җыр-дайна иде.
Ә ямена нәрсәң тиң урманда аткан таңның?!
Шуны күргәч, башактай баш ия иде жаның.
...Ә хәзер бернәрсә юк... Исләрең китә карап:
Анда-санда күренә берничә кәрлә нарат.
...Ә картлар хәтерли бит: моңда үскән урманны,
Күләгә итеп җиргә урман җәйгән юрганны.
...Килә коры ел – ачлык. Кибә-шешенә халык.
Ипине сала мүктән, кайры пешерә халык.
Һәм урман кисә халык, куз яше түгә-түгә,
Аударалар агачны, кәүсәсен убә-үбә.
Аяктан еккач, алар жирдә бик аз яталар –
Урман юк якка илтеп арзан хакка саталар.
...Сүз шунда бетте. Ләкин йөрәктә әрнү сүнмәс,
Шундый зур һәлакәткә, юк, күнми йөрәк, күнмәс.

*Į totorių kalbą vertė* ***Zaki Nuri***